**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 4 февралендәге 316 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 30 декабрендәге 4797 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2025 елның 17 декабрендәге 5-4 номерлы “2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында”гы карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы карарына үзгәреш кертү турында**

Казан шәһәре Думасының 2025 елның 17 декабрендәге 5-4 номерлы «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карарын үтәү һәм мәгълүмат тапшыру вакытын төгәлләштерү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 30 декабрендәге 4797 номерлы «Казан шәһәре Думасының 2025 елның 17 декабрендәге 5-4 номерлы «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында»гы карарына, 8.3 пункчасын түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«8.3. ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 нчы көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Казан шәһәренең муниципаль ихтыяҗлары өчен тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү буенча үткәрелгән сәүдә процедуралары нәтиҗәсендә ирешелгән экономия турында мәгълүмат (төзелгән муниципаль контрактлар буенча) тапшырырга».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**